ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Постановление** **Карар**

№ 050 от «20» 04 2026 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы каршында инвестиция Советы төзү турында

Татарстан Республикасы “Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү максатында, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ Федераль Закон, “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 январендәге № 7-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, “2023-2028 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү” муниципаль программасы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы каршында инвестиция Советы (алга таба- инвестиция Советы) төзергә.
2. Инвестиция Советы составын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.
3. Инвестиция Советы турындагы нигезләмәне әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә расларга.
4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Инвестиция Советын төзү турында» 22.12.2015 елның 22 декабрендәге 137 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.
5. Опубликовать Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми http://mamadysh.tatarstan.ru// рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе Е.Г. Борисовка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы В.И. Никитин

000050

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башлыгының
«20» 04 2026 ел, № 036
карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы каршында инвестиция Советы составы

Никитин Вадим Ильич - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы, Инвестиция Советы рәисе

Борисов Евгений Геннадьевич - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе, Инвестиция Советы рәисе урынбасары

Абдуллина Лира Ленар кызы – Баш белгеч ( Совет секретаре)

Совет әгъзалары:
Никифоров Руслан Михайлович - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының беренче урынбасары (килешү буенча)

Нәфыйков Таһир Габдулла улы - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Фәтхуллин Илдар Мөхәмметәтнур улы - Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый эш бүлеге башлыгы (килешү буенча)

Һадиуллин Ленар Хәлим улы - Мамадыш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча)

Гаптрахимов Ильяс Габделхай улы - Мамадыш муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча)

Леонтьева Марина Сергеевна – Мамадыш районында шәхси эшкуар, эшкуарлар хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча)

Нурмөхәммәтов Айдар Нуриәхмәт улы – “ЭПУ Алабугагаз” Мамадыш РЭГС җитәкчесе (килешү буенча)

Галимханов Заһир Таһир улы –Мамадыш РЭСы җитәкчесе (килешү буенча)

Миннәхмәтов Раиф Ринат улы – «Мамадыш водоканалы»АҖ директоры (килешү буенча)

Галимов Хәлим Харис улы – Мамадыш шәһәрендә Ак барс банкы идарәчесе (килешү буенча)

Львова Валентина Павловна – Мамадыш шәһәрендә Саклык банкы идарәчесе (килешү буенча)

Юсупова Эльвира Илсур кызы - Мамадыш шәһәрендә Россельхозбанк идарәчесе(килешү буенча)

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башлыгының
«20» 04 2026 ел, № 050
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы каршында инвестиция Советы турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Мамадыш муниципаль районы башлыгы каршындагы Инвестиция Советы (алга таба — Совет) район территориясендә инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарының, эшкуарлар бергәлегенең һәм инвесторларның үзара хезмәттәшлеге максатларында төзелгән даими эшләүче коллегиаль киңәшмә органы булып тора.
1.2. Совет үз эшчәнлегендә РФ Конституциясенә, федераль законнарга (шул исәптән «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 39-ФЗ номерлы ФЗ), Татарстан Республикасы законнарына, Мамадыш муниципаль районы Уставына, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.
1.3. Совет үз эшчәнлеген ирекле булу, аның әгъзаларының тигез хокуклы булуы, хәбәрдарлык һәм законлылык принципларында алып бара. Совет карарлары тәкъдим итү характерында була һәм тиешле муниципаль хокукый актлар яисә оешмалар адресына мөрәҗәгатьләр кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 2. Советның максатлары һәм бурычлары

2.1. Советны төзүнең төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:
· Мамадыш районы территориясендә уңайлы инвестицион климат булдыру.
* Администрация, инвесторлар һәм ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар арасында нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итү.
· Инвестицияләр җәлеп итү һәм яңа проектларны гамәлгә ашыру исәбенә районның тотрыклы социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итү.
2.2. Советның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
· Мамадыш районы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү буенча тәкъдимнәр эшләү.
· Район территориясендә гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителә торган инвестиция проектларын карау һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга ярдәм итүнең максатка ярашлылыгы турында бәяләмәләр әзерләү.
· Проектларны гамәлгә ашырганда (Килештерү, җир кишәрлекләре бүлеп бирү, челтәрләргә тоташтыру) инвесторларда барлыкка килә торган

проблемалы мәсьәләләрне оператив хәл итүдә һәм административ киртәләрне бетерүдә ярдәм итү.
· Салым җыюны җайга салу, инвестиция эшчәнлеге субъектларына ташламалар һәм муниципаль гарантияләр бирү өлешендә районның норматив-хокукый актларын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.
· Инвестиция килешүләре һәм муниципаль-хосусый партнерлык төзү буенча тәкъдимнәрне карау.
· Инвестиция әйләнешенә җәлеп итү өчен мөмкин булган инвестиция мәйданчыкларын һәм муниципаль милек объектларын сайлап алуда ярдәм итү.
· Инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда районның хезмәт, табигать һәм энергетика ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелегенә анализ ясау.

## 3. Советның составы һәм структурасы

3.1. Совет составы Мамадыш муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.
3.2. Совет район администрациясе вәкилләреннән (икътисад, мөлкәт мөнәсәбәтләре, архитектура, авыл хуҗалыгы бүлекләре), эшкуарлык җәмәгатьчелеге, банк секторы, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар вәкилләреннән (килешү буенча) төзелә .
3.3. Совет составына түбәндәгеләр керә:
· Советы рәисе - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы (совет эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырышлар алып бара);
Совет рәисе урынбасары - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе,
Совет секректаре- территориаль үсеш бүлеге белгече(оештыру-техник тәэмин итү, материаллар әзерләү һәм беркетмәне алып бару өчен җавап бирә).

Совет әгъзалары - Башкарма комитетның структур бүлекчәләре вәкилләре һәм чакырылган затлар.

## 4. Советның вәкаләтләре (хокуклары)

Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен Советн түбәндәгеләргә хокуклы:
4.1. Район хакимияте органнарыннан, предприятиеләрдән һәм оешмалардан совет компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга.
4.2. Утырышларда катнашу өчен экспертлар, күзәтчелек органнары һәм иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә.
4.3. Сорауларны алдан карау һәм инвестиция проектларына анализ ясау өчен Совет әгъзалары һәм чакырылган белгечләрдән эшче төркемнәр төзергә.
4.4. Инвесторларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында район башлыгы һәм район Советы адресына тәкъдимнәр кертергә.

## 5.Эшне оештыру

5.1. Совет утырышлары кирәк булган саен, ләкин кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк уздырылмый.

5.2. Утырышта Совет Әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыграгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип санала.
5.3. Карарлар ачык тавыш бирү юлы белән катнашучы әгъзаларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.
5.4. Карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул рәислек итүче һәм секретарь тарафыннан имзалана. Беркетмәләр Башкарма комитетның икътисад бүлегендә саклана.
5.5. Совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.